МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

г.Казань

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ
азык-төлек
МИНИСТРЛЫГЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБ...
ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛ...

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.02.2016 **№** 18/2-пр.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан хәбәр итү тәртибе турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә һәм Россия Федерациясе Президентының «Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар тарафыннан хәбәр итү тәртибе турында һәм коррупциягә каршы тору максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына һәм башка федераль законнарга үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указын үтәү йөзеннән,

**б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының кадрлар бүлеге башлыгы А.З.Кашаповка дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән имза куйдырып таныштырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л.Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының 2016
елның 19 февралендәге № 18/2-пр
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан хәбәр итү тәртибе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында (алга таба - Министрлык) вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба - граждан хезмәткәре), аларны эшкә алучының - Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының (алга таба - министр) вәкиле тарафыннан хәбәр итү тәртибен билгели.

2. Хәбәр вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәрнамә (алга таба - хәбәрнамә) рәвешендә граждан хезмәткәре тарафыннан язмача, әлеге Нигезләмәгә Кушымтада китерелгән форма буенча төзелә һәм министрга җибәрелә.

3. Министр өч эш көне эчендә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба - җаваплы зат) алдан карау өчен хәбәрнамә җибәрә.

4. Хәбәрнамәне алдан карау барышында җаваплы зат хәбәрнамә җибәргән граждан хезмәткәреннән анда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга, дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга билгеләнгән тәртиптә гарызнамәләр җибәрү инициативасын белдерергә хокуклы.

5. Җаваплы зат алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Хәбәрнамә, бәяләмә һәм алдан карау барышында алынган башка материаллар җаваплы зат тарафыннан хәбәрнамә алынган көннән җиде эш көне эчендә Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе (алга таба - Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән гарызнамәләрне җибәргән очракта, хәбәрнамә, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан хәбәрнамә кергән көннән 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыкка түгел.

7. Хәбәрнамә, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан Министрлык боерыгы белән расланган Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган

таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турындагы Нигезләмә нигезендә карала.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Премьер министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

____________________________________________

(Ф.И.Ат.ис.)

кемнән ________________________________________

____________________________________________

(вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис., телефон номеры)

**Вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында**
**ХӘБӘРНАМӘ**

Миндә вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган *(тиешлесенең астына сызарга)* шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүгә нигезләр булган хәлләр: _______________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Башкаруга шәхси кызыксынучанлык тәэсир итә яисә тәэсир итәргә мөмкин булган вазыйфаи бурычлар: ______________________________________

______________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын бетерү яисә җайга салу буенча тәкъдим ителүче чаралар: ____________________________________________________

______________________________________________________________________________

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе утырышында әлеге хәбәрнамәне караганда шәхсән катнашырга ниятлим/ниятләмим (тиешлесенең астына сызарга).

"____"______________20___ел __________________________ ___________________________

(имза) (имзаның расшифровкасы)